| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.03.2020 № 349-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отрядын төзү турында

Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенең “Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряды турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 2020 елның 21 гыйнварындагы 02-20-р номерлы боерыгын үтәү йөзеннән, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отрядын төзергә.
2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряды турындагы Нигезләмәне расларга.
3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
_______________________
_______________________
номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряды турында Нигезләмә**

**1. Гомуми нигезләмәләр.**

1.1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряды турында Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Эпизоотиягә каршы чорда һәм эпизоотия чорында Татарстан Республикасында кошлар гриппын профилактикалау һәм бетерү буенча комплекслы чаралар планы турында “ 2006 елның 1 апрелендәге 412-р номерлы боерыгы һәм Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенең “Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряды турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 2020 елның 21 гыйнварындагы 02-20-р номерлы боерыгы нигезендә эшләнде.

1.2. Әлеге Нигезләмә, хайваннар һәм кеше өчен уртак авырулар таралу учакларын локальләштерүгә һәм бетерүгә юнәлдерелгән эпизоотиягә каршы чаралар комплексын үткәрү, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә эпизоотияләр (дуңгызларның африка чумасы, югары патогенлы кош гриппы, Себер түләмәсе, котыру авыруы һ.б.) аркасында килеп чыккан гадәттән тыш хәлләрне (алга таба – гадәттән тыш хәлләр) локальләштерү һәм бетерү буенча эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отрядларны куллануның гамәли тәҗрибәсе нигезендә аларның нәтиҗәләрен минимальләштерү максатларында, Саба муниципаль районының (алга таба - муниципаль район) эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отрядын (алга таба – отряд) булдыру һәм эшләтү тәртибен билгели.

1.3. Отряд штаттан тыш формирование булып тора һәм Саба муниципаль районында Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә төзелә.

1.4. Отряд составында төзелә торган функциональ бүлекчәләр (төркемнәр, звенолар, расчетлар һ.б.) саны әлеге Нигезләмәнең 1 кушымтасында китерелгән.

1.5. Отряд үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында” 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, “Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында” 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон, “Ветеринария турында” 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, 1995 елның 4 декабрендәге 13-7-2/469 номерлы биологик калдыкларны җыю, утильләштерү һәм юк итү буенча ветеринария-санитария кагыйдәләре, “Дуңгызларда африка чумасы чыганакларының таралуын булдырмауга һәм бетерүгә юнәлдерелгән

профилактик, диагностик, чикләү һәм башка чараларны гамәлгә ашыру, карантин һәм башка чикләүләрне билгеләү һәм бетерүнең ветеринария кагыйдәләрен раслау турында” Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 31 маендагы 213 номерлы боерыгы һәм кеше иминлеге, хайваннар (кошлар) авыруларын профилактикалау, бетерү өлкәсендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы территориясенә дуңгызларның африка чумасы (югары патогенлы кошлар гриппы) авыруларының үтеп керүенә һәм аларның таралуына юл куймау буенча республика штабы карарлары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.6. Отряд Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең территориаль учреждениеләре (алга таба – муниципаль берәмлекләрнең дәүләт ветеринария берләшмәләре) (килешү буенча), кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекләре (килешү буенча), ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасының биологик ресурслар буенча Дәүләт комитеты (килешү буенча), “Татарстан Республикасында Гигиена һәм эпидемиология үзәге” ФБУСС филиаллары (килешү буенча), сәламәтлек саклау учреждениеләре (килешү буенча), полиция бүлекләре һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча муниципальара бүлекләренең юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча дәүләт инспекциясе бүлекләре (килешү буенча), коммуналь хезмәтләр, җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасында территориаль ирекле янгын сагы яисә федераль янгынга каршы хезмәтнең (алга таба – ДЯХ ФЯХ) территориаль бүлекчәләре (килешү буенча) белгечләре арасыннан төзелә.

1.7. Отряд расланган план нигезендә дәвалау, ветеринария-санитария, эпизоотиягә каршы, эпидемиягә каршы, чикләү (карантин) һәм башка чаралар комплексын башкара.

1.8. Башкарма хакимиятнең территориаль органнары карары буенча, йогышлы учакта эшләрне үткәрү чорына отрядның барлык шәхси составына эпидемия күрсәткечләре буенча ашыгыч иммунопрофилактика үткәрелергә тиеш.

## 2. Отрядның бурычлары.

2.1. Отряд Саба муниципаль районы территориясендә кошлар (хайваннар) авыруы ситуациясен тикшерү, шулай ук эпизоотияләр һәм кошлар һәм хайваннарның йогышлы булмаган этиологиядән күпләп үлүе (авыруы) белән бәйле гадәттән тыш хәлләрне локальләштерү һәм бетерү буенча чаралар комплексын үтәү өчен төзелә.

2.2. Отрядның бурычлары этаплап билгеләнә.

**2.2.1.**. Беренче этап – авыруны кузгатучының төрен яисә кешеләрнең авыруы һәм хайваннарның (кошларның) күпләп үлү сәбәпләрен ачыклаганчы.

**2.2.2.** Икенче этап – авыруны кузгатучының төре ачыкланганнан һәм ахыргы диагноз куелганнан соң.

2.3. <u>Отрядның беренче этаптагы бурычлары:</u>

– медицина, ветеринария һәм эпидемиологик разведканы гамәлгә ашыру;

– эпидемиологик һәм эпизоотик хәлне бәяләү; контактлы, көчсезләнгән һәм авыру хайваннарны (кошларны) аулау (алга таба - авыру хайваннар (кошлар);

– һәлак булган, клиник авырулы хайваннардан һәм кошлардан патологик

материал сайлап алу;

– тикшерүләр үткәрү өчен махсуслаштырылган лабораторияләргә пробалар китерү;

– җиһазлар, инвентарь, биналар һәм территорияләрнең агымдагы һәм йомгаклау дезинфекциясен үткәрү;

– биналарны һәм территорияләрне механик чистарту.

2.3. Отрядның икенче этаптагы бурычлары:

– гадәттән тыш хәлләр (карантин) зонасында тәүлек буе пропуск режимын контрольдә тоту;

– гадәттән тыш хәлләр (карантин) зонасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү; гадәттән тыш хәл (карантин) зонасында булган халык арасында профилактик һәм эпидемиягә каршы чаралар үткәрү);

– барлык авыру хайваннарны (кошларны) тоту һәм сую (эвтаназия) һәм кирәк булганда сәламәт (контакт) хайваннарны һәм кошларны мәҗбүри сую;

– һәлак булган һәм үлгән хайваннарны (кошларны) утильләштерү (юк итү) урыннарына илтү;

– һәлак булган һәм үлгән хайваннарны (кошларны) утильләштерү;

– эпизоотик учакны бетерүдә катнашучы отрядның шәхси составын һәм башка затларны санитар эшкәртү;

– бер тапкыр кулланыла торган саклану чараларын юк итү; агымдагы һәм йомгаклау дезинфекциясе үткәрү;

– хайваннарны һәм башка мөлкәтне тартып алуны раслаучы документлар әзерләү һәм аларның милекчеләренә законнарда билгеләнгән тәртиптә читләштерелгән өчен компенсация түләүләрен алу өчен бирү;

– читләштерү, утильләштерү, юк итү нәтиҗәләре буенча беренчел хисап документларын (актларны) төзү;

– халыкка авыруны профилактикалау чаралары, чикләү чараларын үтәү кагыйдәләре турында аңлату эшләре алып бару, шулай ук хайваннарны (кошларны) читләштергән өчен акчалата компенсацияләр түләү тәртибе турында халыкка мәгълүмат бирү.

## 3. Отрядның оештыру структурасы, бурычлары һәм тәэмин ителеше.

3.1. Отряд турында Нигезләмә һәм аның оештыру структурасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

3.2. Отряд командиры – “Саба район дәүләт ветеринария берләшмәсе” ДБУ башлыгы (килешү буенча).

3.3. Отряд функциональ бүлекчәләрдән тора (төп һәм тәэмин итү ).

– **3.3.1**. Төп бүлекчәләр:

– ветеринария разведкасы төркеме; читләштерү төркеме;

– кыргый хайваннар (кошлар) санын җайга салу төркеме; утильләштерү төркеме; дезинфекция төркеме.

**3.3.2**. Тәэмин итү бүлекчәләре:

– медицина һәм эпидемиология разведкасы төркеме;

– пропуск режимын тәэмин итү төркеме;

– җәмәгать тәртибен саклау төркеме;

– табиб-шәфкать туташлары бригадасы;

– янгын расчеты;

– санитар-юдырту пункты.

3.4. Отрядның оештыру-штат структурасы һәм аны автомобиль һәм махсус техника белән тәэмин итү әлеге Нигезләмәгә 1 һәм 3 кушымталарда тәкъдим ителгән.

**3.4.1. Ветеринария разведкасы төркеме** һәлак булган (авыручы) хайваннарны (кошларны) ачыклау (табу) урынына чыгып, патологик материалдан (кан анализы, патологик материал һәм биоматериал пробаларын сайлап алу тәртибе буенча инструкция нигезендә) пробалар ала, аларны махсуслаштырылган лабораториягә илтә (хайваннар (кошлар) авыруларына тикшерү өчен пробалар китерү тәртибе нигезендә), һәлак булган (авыру) хайваннарны (кошларны) ачыклау (табу) урынына якын булган ишегалларын һәм территорияләрне йөреп чыга, һәлак булган хайваннарны (кошларны) исәпкә алып бара.

Төркем хайваннар (кош-корт) үлү очраклары турында мәгълүмат алганнан соң бер сәгать эчендә имин булмаган пунктка чыга.

Төркем Саба муниципаль районының дәүләт ветеринария берләшмәләре хезмәткәрләре арасыннан төзелә (килешү буенча). Ветеринария разведкасы төркеме командиры отряд командиры урынбасары булып тора.

Төркемнең шәхси составы шәхси саклану костюмнары, сулыш органнарын саклау чаралары белән тәэмин ителә.

Төркемне тәэмин итү: патологик материалны алу өчен инструментлар, патологик материалны транспортлау өчен хладагент булган термоконтейнер, лабораториягә патологик материал юнәлешләре бланклары, мобиль элемтә чаралары, полиэтилен капчыклары, дезинфекция чаралары, кул юу өчен су салынган савыт, сөлгеләр, сабын, бинокль, фонарь, һәлак булган хайваннарны (кошларны) исәпкә алу журналы.

**3.4.2. Читләштерү төркеме** авыру һәм контактлы хайваннарны (кошларны) аулый, кирәк булганда аларны йоклату (эвтаназия) , шулай ук мәетләрне җыю һәм транспортка төяү буенча чаралар үткәрә, утильләштерү урыннарына алып бара һәм үлгән хайваннарны (кошларны) исәпкә алып бара, читләштерү, тартып алу һәм юк итү (утильләштерү) нәтиҗәләре буенча беренчел исәп документларын (актлар) төзи, тартып алуны раслаучы документлар әзерли һәм аларны милекчеләргә компенсация түләүләрен алу өчен бирә.

Төркем Саба муниципаль районының дәүләт ветеринария берләшмәләре, коммуналь хезмәтләр хезмәткәрләре арасыннан төзелә.

Төркемнең шәхси составы сулыш һәм тире органнарын шәхси саклау чаралары белән тәэмин ителә.

Төркемне тәэмин итү: тоту өчен силкалар (сачоклар), полиэтилен капчыклар, йоклату өчен дарулар, шприц-автоматлар, үлгән хайваннарны (кошларны) исәпкә алу һәм үлчәү журналы, үлчәү, калькулятор һәм дезинфекция чаралары, документлар бланклары (актлар).

**3.4.3. Кыргый хайваннарның (кошларның) санын җайга салу төркеме** кыргый фаунада контактлы яки авыру хайваннарны (кошларны) атуны (атуны) гамәлгә ашыра, аларны җыю һәм транспортка төяү буенча чаралар уздыра, тотылган, атылган һәм һәлак булган хайваннарның (кошларны) исәбен ала һәм аларны лаборатор тикшеренүләргә җибәрә.

Төркем Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының дәүләт күзәтчелеге буенча район (районара) бүлекләре хезмәткәрләре

арасыннан төзелә.

Төркемнең шәхси составы сулыш һәм тире органнарын шәхси саклау чаралары белән тәэмин ителә.

Төркемне тәэмин итү: ау мылтыклары, ау пычаклары, амуниция (патронташ, кейслар һ.б.), тоту өчен силкалар (сачоклар), хайваннар (кошлар) мәетләре өчен полиэтилен капчыклар, ату урыннарын теркәү һәм үлгән урыннарны ачыклау белән атылган кыргый хайваннарны (кошларны) исәпкә алу журналы.

**3.4.4. Утильләштерү төркеме** утильләштерү урынын әзерли, утильләштерү урынына хайваннарны (кошларны) бушатуны гамәлгә ашыра, биотермик чокырларда дезинфекция чаралары кулланып яисә янгын һәм шәхси куркынычсызлык чараларын катгый үтәгәндә яндыру юлы белән хайваннар(кошлар) мәетләрен утильләштерүне уздыра, утильләштерелгән хайваннарны (кошларны) исәпкә алып бара.

Төркем Саба муниципаль районының дәүләт ветеринария берләшмәләре һәм коммуналь хезмәтләр хезмәткәрләре арасыннан төзелә (килешү буенча).

Төркем составыннан ветеринария-санитария экспертизасы лабораториясенең ветеринария табибы суелган продуктларга суйган хайваннарны (кошлар) карауның ветеринария тәртипләре һәм ит һәм ит продуктларына ветеринария-санитария экспертизасы үткәрү кагыйдәләре нигезендә бәя бирә.

Төркемнең шәхси составы саклагыч костюмнар, сулыш органнарын саклау чаралары, резин перчаткалар белән тәэмин ителә.

Төркемне тәэмин итү: экскаватор һәм металл кузовлы йөк автомобиле (яки металл сыешлык белән җиһазландырылган автомобиль), дезинфекция чаралары, утильләштерелгән хайваннарны (кошларны) исәпкә алу журналы.

**3.4.5. Дезинфекция төркеме** һәлак булган (авыру) хайваннарны (кошларны) ачыклау урынын механик чистарта, йогышлы учакның агымдагы һәм йомгаклау дезинфекциясен (ветеринария дезинфекциясе, дезинвазиясе, дезинсекциясе һәм дератизациясе үткәрү инструкциясе нигезендә) үткәрә.

Төркем дәүләт ветеринария берләшмәләре хезмәткәрләре, объектлар хезмәткәрләре яки дезинфекция станцияләре хезмәткәрләре арасыннан төзелә.

Төркемнең шәхси составы саклагыч костюмнар, сулыш органнарын саклау чаралары, резин перчаткалар белән тәэмин ителә.

Төркемне тәэмин итү: Комаровның дезинфекцияләү җайланмасы һәм дезинфекция чаралары.

**3.4.6. Медицина һәм эпидемиология разведкасы төркеме** түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

– эпизоотик (йогышлы) учакта һәм янәшәдәге территориядә медицина һәм эпидемиология тикшерүе;

– риск төркеме затларын (хуҗалык хезмәткәрләрен, отрядның шәхси составын һәм учакны бетерүдә катнашучыларны) медицина тикшерүе;

– халык арасында авыручыларны һәм контактлы затларны ачыклау максатыннан якын-тирә җирләрне йөреп чыгу (йогышлы авыру эләктерү шиге булганда);

– йогышлы авыру эләктерү мөмкин булган авыруларга һәм затларга лаборатор тикшерүләр оештыру;

– кирәк булганда ашыгыч профилактиканы оештыру;

– авыру йоктырырга мөмкин булган кешеләрне вакытлыча изоляцияләү;

– учакта агымдагы һәм йомгаклау дезинфекциясе үткәрүне оештыру һәм контрольдә тоту.

Төркем “Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге” ФБУСС филиаллары һәм сәламәтлек саклау оешмалары хезмәткәрләре арасыннан төзелә.

Төркемнең шәхси составы саклагыч костюмнар, сулыш органнарын саклау чаралары, резин перчаткалар белән тәэмин ителә.

Төркемне тәэмин итү: лаборатория тикшеренүләре өчен материал алу өчен сандык, медицина ярдәме күрсәтү өчен күчмә сандык.

**3.4.7. Пропуск режимын тәэмин итү төркеме** гадәттән тыш хәлләр (карантин) зонасында хәрәкәтне җайга салуны оештыра һәм тәэмин итә. Төркем ветеринария-полиция (контроль-үткәрү, санитар-үткәрү) пунктларын (постларны) җиһазлау һәм чыгару өчен билгеләнгән.

Пунктларның һәм постларның саны гадәттән тыш хәлләр зонасына керү (китү) саныннан чыгып билгеләнә. Торак пунктка төп керү (чыгу) урыннарында (объект, гадәттән тыш хәлләр зонасына, карантин зонасына) пунктлар җиһазлана һәм чыгарыла.

Төркем Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча муниципальара бүлекләренең (килештерү буенча) Юл хәрәкәте иминлеге буенча дәүләт инспекциясе бүлекләре һәм (яки) бүлекчәләре, муниципаль берәмлекләрнең дәүләт ветеринария берләшмәләре, Татарстан Республикасы буенча ветеринария һәм фитосанитар күзәтчелек буенча Федераль хезмәт Идарәсе (килешү буенча) хезмәткәрләре арасыннан төзелә.

Пунктны тәэмин итү: җиңел автомобиль, мобиль элемтә чаралары, дезинфекция барьеры, шлагбаум, кешеләрне киендерү урыны, Комаровның дезинфекцияләү җайланмасы яки транспорт чараларын махсус эшкәртү (дезинфекция) өчен башка техника, эш эремәсен әзерләү өчен сыешлык, су өчен сыешлык, дезинфекция чаралары, юынгыч, сөлге, сабын, “Карантин”язулы аншлаг.

Постны тәэмин итү: җиңел автомобиль, мобиль элемтә чаралары, шлагбаум, «Карантин» язулы аншлаг, гадәттән тыш хәлләр зонасын (карантин) әйләнеп чыгуны күрсәтүче юл билгеләре, фонарь.

Төркемнең шәхси составы саклагыч костюмнар, сулыш органнарын саклау чаралары, итекләр, резин перчаткалар белән тәэмин ителә.

**3.4.8.** Җәмәгать тәртибен саклау төркеме карантин зонасында (ГТХ зонасында) тәртип саклауны тәэмин итә, отрядның шәхси составын, беренче чиратта, ветеринария разведкасы, читләштерү, медицина һәм эпидемиология разведкасы төркемнәрен озата баруны һәм саклауны оештыра.

Төркем Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча муниципальара бүлекләре полиция бүлекләре хезмәткәрләре арасыннан төзелә (килешү буенча).

Төркемнең шәхси составы штатлы корал һәм сулыш һәм тире органнарын саклау өчен табель чаралары белән тәэмин ителә һәм җиһазландырыла.

**3.4.9.** Табиб-шәфкать туташлары бригадасы карантин-чикләү чараларын үткәрү чорында отрядның шәхси составына медицина ярдәме күрсәтә, медицина тикшерүе һәм аның сәламәтлеген тикшереп торуны оештыра, кирәк булганда ачыкланган (шикле) авыруларны госпитализацияләүне (изоляцияләүне) оештыра.

Бригада территориаль сәламәтлек саклау учреждениеләре хезмәткәрләре арасыннан төзелә (килешү буенча).

Бригаданың шәхси составы саклагыч костюмнар, халатлар, баш киемнәре һәм битлекләр белән тәэмин ителә.

Бригаданы тәэмин итү: медицина ярдәме күрсәтү өчен табиб (фельдшер) сандыгы һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының җитәкчелек документлары таләпләренә туры китереп башка табельле мөлкәт.

**3.4.10**. Янгын расчеты һәлак булган һәм үлгән хайваннарны (кошларны) яндырганда янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәүне контрольдә тота.

Расчет командиры яндыру урынын сайлауда катнаша . Янгын чыкканда аны сүндерүне оештыра һәм үткәрә.

Янгын расчеты территориаль янгын сүндерү сагы хезмәткәрләре яки Федераль янгынга каршы хезмәтнең территориаль бүлекчәләре (килешү буенча) хезмәткәрләреннән төзелә.

**3.4.11**. Санитар-юдырту пункты шәхси составка һәм милеккә санитар эшкәртү үткәрә.

Пункт торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләре хезмәткәрләре арасыннан төзелә.

Эпизоотик (йогышлы) чыганакны бетерү буенча чаралар тәмамланганнан соң отрядның шәхси составы һәм гадәттән тыш хәлләр (карантин) зонасында эшләргә җәлеп ителгән затлар мәҗбүри санитар эшкәртү уза, ә бер тапкыр кулланыла торган махсус кием яндыру юлы белән юкка чыгарыла.

Пунктны тәэмин итү: Комаровның дезинфекцияләү җайланмасы, күчмә душ җайланмасы, су сыешлыгы, сабын, сөлге, утын.

## 4. Отряд командиры вазифалары.

4.1. Отряд командиры гадәттән тыш хәлләрне бетерү (эпизоотия) буенча чаралар комплексын оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы һәм отрядның барлык шәхси составы өчен туры начальник булып тора.

Отряд командиры әзерлек, дисциплина, йөкләнгән бурычларны үз вакытында һәм сыйфатлы үтәү, отряд бүлекчәләрен (төркемнәрен) шәхси состав белән комплектлау, техника һәм мөлкәт белән тәэмин итү өчен шәхси җаваплылык тота.

Отряд командиры Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенә буйсына.

4.2. Отряд командиры түбәндәгеләрне эшләргә бурычлы:

– йогышлы учакта эпизоотиягә каршы чараларны оештыру һәм алып бару буенча җитәкче документларның таләпләрен белергә һәм үз эшчәнлегендә аларга таянып эш итәргә;

– отрядның шәхси составының функциональ бурычларын эшләүдә һәм аларга төзәтмәләр кертүдә катнашырга;

– йөкләнгән бурычларны үтәгәндә отрядның шәхси составы белән җитәкчелек итәргә; отрядның шәхси составын, аның бурычларын , мөмкинлекләрен, шәхси состав белән комплектлауның, техника һәм барлык милек төрләре белән җиһазландыруның тәртибен белергә;

– эпизоотияне кисәтү һәм бетерү буенча махсус әзерлек дәрәҗәсен, кул астындагы кешеләрнең әхлакый һәм эшлекле сыйфатларын белергә;

– эпизоотик учакны локальләштерү һәм бетерү вакытында отрядның җыелу һәм җәелдерү урыннарын белергә;

– отряд белгечләрен даими рәвештә әзерләүне камилләштерергә, отрядның шәхси составы белән махсус әзерлек буенча дәресләр оештырырга һәм үткәрергә;

– отрядның хәрәкәтләргә әзерлеген күтәрү буенча чаралар үткәрергә, шәхси

составның даими әзерлегенә ярдәм итәргә;

– куелган бурычларны үтәүгә ирешергә, акыллы инициатива күрсәтергә һәм карарлар кабул итәргә;

– милекне һәм махсус техниканы дөрес куллануны, аларның эчтәлеген һәм саклыгын тикшереп торуны башкарырга;

– отрядның шәхси составын шәхси саклау чаралары белән тәэмин итү турында кайгыртырга;

– һәлак булган һәм үлгән хайваннарны (кошларны) утильләштерү урыннарын җирле үзидарә органнары белән килештерергә;

– шәхси составны санитар эшкәртүне, эш (чаралар) төгәлләнгәннән соң техника, мөлкәт һәм җиһазларны дезинфекцияләүне оештырырга ;

– гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча оператив штабка (эпизоотия) учакны локальләштерүгә һәм бетерүгә җәлеп ителә торган көчләрнең һәм чараларның составы, эпизоотиянең торышы, эшләрнең (чараларның) барышы турында мәгълүматны үз вакытында тапшырырга;

– эшләрне (чараларны) үткәрү өчен җәлеп ителә торган көчләрнең һәм чараларның составын үзгәртү (чамадан тыш төркемләү) буенча үз вакытында карарлар кабул итәргә, аларны Башкарма комитет җитәкчесе белән килештерергә;

– муниципаль берәмлекнең гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе җитәкчесенең эпизоотияләр аркасында барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр режимнарын кертү турында карарын эшләү өчен тәкъдимнәр тапшырырга;

– отряд бүлекчәләренең ихтыяҗларын билгеләү һәм белү һәм техника, матди, дезинфекция һәм башка чаралар белән тәэмин итүгә үз вакытында гариза бирергә;

– матди чараларны исәпкә алуны, саклауны һәм куллануны оештырырга һәм контрольдә тотарга;

– отрядның шәхси составы белән елга бер тапкырдан да ким булмаган вакытта укулар һәм өйрәнүләр үткәрергә;

– отрядның шәхси составы өчен куркынычсызлык таләпләрен билгеләргә һәм аларның үтәлешен контрольдә тотарга, эшләрне (чараларны) үткәргәндә аларның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә;

– Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә һәм башка югары органнарына үткәрелгән чаралар турында хисаплар һәм белдермәләр җиткерергә.

## 5. Отряд белгечләренең функциональ бурычлары.

5.1. Отряд белгечләренең функциональ бурычлары отряд командиры тарафыннан аның составына керүче бүлекчәләрнең (төркемнәрнең) командирлары белән берлектә эшләнә һәм, отряд эшчәнлегенең төрле режимнарында биологик (ветеринария, эпизоотик) хәл үсешенең мөмкин булган сценарийларыннан чыгып, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан раслана.

## 6. Отрядны әзерлеккә китерү тәртибе.

6.1. Отряд Саба муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе карары буенча әзерлеккә китерелә.

6.2. Гадәттән тыш хәлләр (карантин) зонасында эшләү өчен җәлеп ителә торган көчләрнең һәм чараларның составы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан отряд командиры тәкъдиме белән билгеләнә һәм ул гадәттән тыш хәлләр үсешенә китергән авыру төренә (аеруча куркыныч инфекция) һәм башкарыла торган бурычлар күләменә бәйле.

6.3. Отрядның шәхси составына хәбәр итү һәм аны җыю өчен, әлеге Нигезләмәнең 5 кушымтасы нигезендә, муниципаль берәмлекнең дәүләт ветеринария берләшмәсе буенча дежур торучыга инструкция эшләнә һәм раслана.

6.4. Сигнал алу мизгеленнән әзерләнү өчен гомуми вакыт түбәндәгеләрне тәшкил итә:

эш вакытында: отряд-2 сәгатьтән артык түгел, ветеринария разведкасы төркеме-бер сәгатьтән дә артык түгел;

ял вакытында: отряд-4 сәгатьтән артык түгел, ветеринария разведкасы төркеме – 2 сәгатьтән артык түгел.

6.5. Бүлекчәләрнең (төркемнәрнең) командирлары җыелу урынына килеп җитү буенча отряд командирына шәхси составның килүе турында хәбәр итәләр, табельле милек һәм шәхси саклану чаралары бирүне һәм алуны оештыралар, отряд командирына бурычларны үтәүгә әзерлек турында хәбәр итәләр.

6.6. Отряд командиры отрядны әзерлеккә китерү буенча чараларны тәмамлау буенча Башкарма комитет Җитәкчесенә хәбәр итә.

## 7. Отрядның эш режимнары.

7.1. Саба муниципаль районы территориясендәге биологик (ветеринария, эпизоотик) хәлгә карап, отряд өчен түбәндәге эш режимнарының берсе билгеләнә:

югары әзерлек режимы-хайваннарның (кошларның) үлүе ачыкланган мизгелдән диагноз куелганчыга кадәр (үтәлә торган бурычларның беренче этабына туры килә);

биологик-социаль характердагы гадәттән тыш хәл режимы (алга таба-эпизоотия режимы) - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының аерым территорияләрендә, аларның авыру буенча имин булмавы һәм авыру таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, чикләү чаралары (карантин) билгеләү (башкарыла торган бурычларның икенче этабына туры килә).

## 8. Отрядның шәхси составын әзерләү.

8.1. Отрядка кергән белгечләрнең штаттагы вазифасы буенча эш тәҗрибәсе булырга тиеш.

8.2. Отрядның шәхси составын әзерләүнең төп методлары булып инструктор-методик дәресләр, практик күнегүләр һәм өйрәнүләр тора.

8.3. Шәхси состав белән инструктор-методик дәресләрдә куркынычсызлык чараларын үтәү мәсьәләләренә, беренче чиратта эпизоотик (йогышлы) учакта эшләгәндә шәхси составны йогышландыруны профилактикалауга, сулыш һәм тире органнарын шәхси саклау чараларыннан файдалану кагыйдәләренә аерым игътибар

бирелә.

8.4. Шәхси состав белән инструктор-методик дәресләрне төркем командирлары, укулар һәм өйрәнүләрне отряд командиры үткәрә.

8.5. Отрядның шәхси составын әзерләү өчен отряд командиры җавап бирә.

## 9. Матди-техник һәм финанс яктан тәэмин итү.

9.1. Отрядның матди-техник һәм финанс ягыннан тәэмин ителеше отрядның тиешле функциональ бүлекчәләрен (төркемнәрен) формалаштыручылар һәм Саба муниципаль районы чаралары хисабына гамәлгә ашырыла.

9.2. Эпизоотия режимында эшләү өчен билгеләнгән һәм көндәлек эшчәнлектә файдаланылмый торган приборлар, лаборатор җиһазлар, реактивлар, саклану чаралары, дезинфекция һәм башка чаралар запаслары, отряд командиры карары нигезендә махсус биналарда саклана, төзек хәлдә тотыла һәм билгеләнгән тәртиптә чистартыла.

## 10. Отряд документлары исемлеге

10.1. Һәр отрядта отряд командирында булган документларның мәҗбүри исемлеге формалаша.

10.2. Отряд документларын алып бару һәм дөрес рәсмиләштерү өчен отряд командиры җавап бирә.

10.3. Отряд документлары исемлеге:

– Саба муниципаль районы Башкарма комитетының эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отрядын булдыру һәм комплектлау турындагы карары;

– отрядның оештыру-штат структурасы (1 кушымта);

– отрядның шәхси составы исемлеге (2 кушымта);

– отряд составына кертелгән автомобиль һәм махсус техника исемлеге (3 кушымта);

– отрядның шәхси составына хәбәр итү схемасы (4 кушымта);

– муниципаль берәмлек дәүләт ветеринария берләшмәсе дежур торучысының отрядның шәхси составына хәбәр итү һәм аны җыю буенча инструкциясе (5 кушымта).

11. Шәхси состав буенча мәгълүматларны тәгәлләштерү (корректировкалау) ярты елга бер тапкырдан да ким булмаган вакыт белән, шулай ук укулар, өйрәнүләр алдыннан һәм оештыру-штат чаралары вакытында үткәрелә.

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районының
эпизоотиягә каршы җыелма
мобиль отряды турындагы
Нигезләмәгә 1 кушымта

## Организационно-штатная структура отряда

**Командир – 1**
легковой автомобиль –1 ед.

**Группа ветеринарной разведки:**
- командир (зав. ветер. лабораторией) – 1 чел.
- лаборант –1 чел., - водитель – 1 чел.
легковой автомобиль – 1 ед.

**Группа регулирования численности диких животных (птиц):**
- командир – 1 чел., - охотники – 2 чел.,
- водитель – 1 чел., автомобиль – 1 ед.

**Группа отчуждения:**
-командир группы (врач-эпизоотолог) – 1 чел.
-водитель – 4 чел.
-ловцы – 4 чел.
-учётчик –1 чел.
-представитель финансового отдела МО* – 1 чел.
грузовой автомобиль – 4 ед.

**Группа утилизации:**
- командир группы (представитель коммунальной службы МО*) – 1чел.
- утилизатор – 4 чел.
- водитель-экскаваторщик – 1 чел.
- учётчик – 1 чел.
- ветер.-санитар. эксперт – 1 чел.
- водитель груз.автомобиля – 1 чел.
грузовой автомобиль – 1 ед.

**Группа медицинской и эпидемиологической разведки:**
- командир группы (врач – инфекционист) – 1чел.
- врач-эпидемиолог – 1 чел.
- фельдшер – 1 чел.
- водитель – 1 чел.
легковой автомобиль – 1 ед.

**Группа дезинфекции:**
- командир (дезинфектор) – 1 чел.
- лаборант – 1 чел.
- дезинфектор – 1 чел.
- водитель-дезинфектор – 1 чел.
дезинфекционная установка Комарова – 1 ед.

**Группа обеспечения пропускного режима:**
- командир группы – 1 чел.
- регулировщик –** (сотрудн. органов внутренних дел (ГИБДД, полиции)
- дезинфектор – 1чел.
водитель-дезинфектор – 1 ч.
автомобиль патрульно-постовой службы –**
дезинфекционная установка Комарова – 1 ед.

**Группа охраны общественного порядка:**
- командир группы – 1 чел.
- сотрудники органов внутренних дел (полиции) – 5 чел.
- водитель – 2 чел.
автомобиль – 2 ед.

**Санитарно-обмывочный пункт:**
- командир пункта (представитель коммунальн. службы МО*) – 1 чел.
- истопник (кочегар) – 2 чел.
водитель – 2 чел.
дезинфекционная установка Комарова – 1 ед.
Передвижная душевая установка – 1 ед.

**Врачебно-сестринская бригада:**
- командир бригады (врач) – 1 чел.
- фельдшер – 1 чел.
- медсестра – 1 чел.
- водитель – 1 чел.
санитарный автомобиль – 1 ед.

**Пожарный расчет:**
- командир расчета – 1 чел.
- пожарные – от 3 чел.
- водитель – 1 чел.
Техника:
АЦ – 1 ед.

**ИТОГО: личного состава – от 59 чел. и более, техники – от 17 ед. и более.**

Примечание: МО* – муниципальное образование;
** – в зависимости от количества въездов (выездов) в населенный пункт (объект, зону ЧС, карантина).

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районының
эпизоотиягә каршы җыелма
мобиль отряды турындагы
Нигезләмәгә 2 кушымта

**Отрядның шәхси составы исемлеге**

| № п/п | Вазифа | Ф.И.АИ. | Эш урыны | Хезмәт телефоны | Өй адресы, кәрәзле телефон | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | ветеринария лабораториясе мөдире | Шәфиков М.В. | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | 2-30-93 | | |
| 2 | ветеринария табибы | Шәмсевәлиев И.И. | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | 2-30-93 | | |
| 3 | ветеринария табибы | Шәмсетдинов И.Ш. | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | 2-30-93 | | |
| 4 | серолог | Мусина Р.Н. | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | 2-30-93 | | |
| 5 | машина йөртүче | Гыймалтдинов И.И. | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | 2-30-93 | | |
| 6 | эпизоотолог | Павлов С.В. | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | 2-30-93 | | |
| 7 | ветеринария табибы | Хәйретдинов А.Г. | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | 2-30-93 | | |
| 8 | ветеринария санитары | Шакиров И.Р. | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | 2-30-93 | | |
| 9 | бухгалтер | Латыпова Г.Ф. | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | 2-30-93 | | |
| 10 | бухгалтер | Гатауллин И.К. | “Саба” авыл хуҗ. җитештерү кооперативы | 2-33-34 | | |
| 11 | машина йөртүче | эчке расписание буенча | “Саба торак-ком. хуҗ.куптармаклы җитештерү предпр. ”АҖ | 2-44-64 | | |
| 12 | машина йөртүче | эчке расписание буенча | “Саба торак-ком. хуҗ.куптармаклы җитештерү предпр. ”АҖ | 2-44-64 | | |
| 13 | начальник урынбасары | Хисмәтов М.М. | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | 2-30-93 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 14 | ветеринария санитария эксперты | Нәгыймов А.З. | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | 2-30-93 | | |
| 15 | ветеринария табибы | Дәүләтов Р.И. | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | 2-30-93 | | |
| 16 | ветеринария санитары | Гатиятуллин Р.Р. | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | 2-30-93 | | |
| 17 | машина йөртүче | эчке расписание буенча | “Саба торак-ком. хуж.куптармаклы җитештерү предпр. ”АҖ | 2-44-64 | | |
| 18 | белгеч-эксперт | Вәгыйзова В.Т. | ТР буенча Роспотребнадзор идарәсенең Саба, Мамадыш, Кукмара, Теләче районнарындагы тер. бүлеге | 2-39-40 | | |
| 19 | санитар-эпидемиологик бүлек мөдире | Хәбибуллина Л.В. | “ТР да Гигиена һәм эпидемиология үзәге” ФБССУнең Саба, Кукмара, Мамадыш районнарындагы бүлеге | 2-44-90 | | |
| 20 | табиб-эпидемиолог | Фасхетдинов И.Р. | “ТР да Гигиена һәм эпидемиология үзәге” ФБССУнең Саба, Кукмара, Мамадыш районнарындагы бүлеге | 2-44-90 | | |
| 21 | табиб ярдәмчесе | Әүхәдиева А.Н. | “ТР да Гигиена һәм эпидемиология үзәге” ФБССУнең Саба, Кукмара, Мамадыш районнарындагы бүлеге | 2-44-90 | | |
| 22 | инфекционист | Гарипов И.М. | “ТР да Гигиена һәм эпидемиология үзәге” ФБССУнең Саба, Кукмара, Мамадыш районнарындагы бүлеге | 2-44-90 | | |
| 23 | машина йөртүче | Ризванов И.Г. | “ТР да Гигиена һәм эпидемиология үзәге” ФБССУнең Саба, Кукмара, Мамадыш районнарындагы бүлеге | 2-44-90 | | |
| 24 | ветеринария табибы | Әхмәтвәлиев Ф.Ф. | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | 2-30-93 | | |
| 25 | ветеринария табибы | Мөхәммәтов М.Р. | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | 2-30-93 | | |
| 26 | дезинфектор | Бәдретдинов И.М. | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | 2-30-93 | | |
| 27 | ветеринария инспекторы | Гарипов И.Г. | ТР Министрлар кабинетының Баш вет. идарәсе дәүләт вет. инспекциясенең Саба тер. бүлеге | 2-53-78 | | |
| 28 | ЮХИДИ инспекторы | эчке расписание буенча | Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча ЮХИДИ бүлеге | 2-32-02 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 29 | ЮХИДИ инспекторы | эчке расписание буенча | Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча ЮХИДИ бүлеге | 2-32-02 | | |
| 30 | УРСХН инспекторы | Хәйруллин Р.М. | ТР буенча УРСХН территориаль бүлеге | (884364)2-94-84 | | |
| 31 | ветеринария табибы | Закаров Д.В. | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | 2-30-93 | | |
| 32 | ветеринария табибы | Мәсгутов И.М. | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | 2-30-93 | | |
| 33 | участок полициясе хезмәткәре | Эчке расписание буенча | Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлеге | 2-32-02 | | |
| 34 | полиция хезмәткәре | Эчке расписание буенча | Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлеге | 2-32-02 | | |
| 35 | полиция хезмәткәре | Эчке расписание буенча | Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлеге | 2-32-02 | | |
| 36 | полиция хезмәткәре | Эчке расписание буенча | Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлеге | 2-32-02 | | |
| 37 | полиция хезмәткәре | Эчке расписание буенча | Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлеге | 2-32-02 | | |
| 38 | дезинструктор-эпидемиолог ярдәмчесе | Галиәхмәтова Ф.Х. | “ТР да Гигиена һәм эпидемиология үзәге” ФБССУнең Саба, Кукмара, Мамадыш районнарындагы бүлеге | 2-44-90 | | |
| 39 | медицина дезинфекторы | Сәетова Л.Н. | “ТР да Гигиена һәм эпидемиология үзәге” ФБССУнең Саба, Кукмара, Мамадыш районнарындагы бүлеге | 2-44-90 | | |
| 40 | табиб | Әхмәтшин Р.Л. | “Саба район үзәк хастаханәсе” ДАСУ | 2-33-03 | | |
| 41 | фельдшер | Ибраһимова Л.М. | “Саба район үзәк хастаханәсе” ДАСУ | 2-33-03 | | |
| 42 | машина йөртүче | Халиев И.Р. | “Саба район үзәк хастаханәсе” ДАСУ | 2-33-03 | | |
| 43 | янгын сүндерү бүлеге командиры | Эчке расписание буенча | “ТР буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 129 янгын бүлеге” ФДКУ | 2-32-01 | | |
| 44 | янгын сүндерүче | Эчке расписание буенча | “ТР буенча федераль янгынга | 2-32-01 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | каршы хезмәтнең 129 янгын бүлеге” ФДКУ | | | |
| 45 | янгын сүндерүче | Эчке расписание буенча | “ТР буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 129 янгын бүлеге” ФДКУ | 2-32-01 | | |
| 46 | егерь -аучы | Асатов Р.Р. | “Саба өйрәнү-сынау урман хуҗалыгы” ДБУ | 4-42-17 | | |
| 47 | егерь | Шәрипов З.А. | “Саба өйрәнү-сынау урман хуҗалыгы” ДБУ | 4-42-17 | | |
| 48 | егерь | Мәҗитов И.И. | “Саба өйрәнү-сынау урман хуҗалыгы” ДБУ | 4-42-17 | | |
| 49 | егерь | Газизҗанов Р.Н. | “Саба өйрәнү-сынау урман хуҗалыгы” ДБУ | 4-42-17 | | |
| 50 | егерь | Яковлев В.А. | “Саба өйрәнү-сынау урман хуҗалыгы” ДБУ | | | |

**Отряд командиры ________________________ З.Р. Ганиев**

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районының
эпизоотиягә каршы җыелма
мобиль отряды турындагы
Нигезләмәгә 3 кушымта

**Отрядның автомобиль һәм махсус техника исемлеге**


| № п/п | Техниканың тибы, маркасы һәм моделе | Техника каян бирелә (оешма исеме) | Дәүләт теркәү билгесе | Машина йөртүченең Ф.И.АИ. | Машина йөртүченең телефоны | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Lada Largus җиңел машинасы | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | А592ХН | Ганиев З. Р. | 2-30-93 | |
| 2 | Lada Largus җиңел машинасы | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | У968НУ | Гыймалдинов И. И. | 2-30-93 | |
| 3 | эчке расписание буенча махсус йөк автомобиле | “Саба торак-ком. хуҗ.куптармаклы җитештерү предпр. ”АҖ | Эчке расписание буенча | Эчке расписание буенча | 2-44-64 | |
| 4 | эчке расписание буенча махсус трактор-төягеч | “Саба торак-ком. хуҗ.куптармаклы җитештерү предпр. ”АҖ | Эчке расписание буенча | Эчке расписание буенча | 2-44-64 | |
| 5 | LADA Granta җиңел машинасы | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | Х060НО | Хәйретдинов А. Г. | 2-30-93 | |
| 6 | эчке расписание буенча махсус экскаватор | “Саба торак-ком. хуҗ.куптармаклы җитештерү предпр. ”АҖ | Эчке расписание буенча | Эчке расписание буенча | 2-44-64 | |
| 7 | LADA 4x4 җиңел машинасы | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | О066СА | Дәүләтов Р. И. | 2-30-93 | |
| 8 | LADA Granta җиңел машинасы | “ТР да Гигиена һәм эпидемиология үзәге” ФБССУнең Саба, Кукмара, Мамадыш районнарындагы бүлеге | В300ТМ | Ризванов И. Г. | 2-44-90 | |
| 9 | махсус ГАЗ-3309 ДУ-2ГД | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | О495СА | Бәдретдинов И. М. | 2-30-93 | |
| 10 | LADA Granta җиңел машинасы | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | Х980НО | Шәфыйков М. В. | 2-30-93 | |
| 11 | эчке расписание буенча җиңел машина | Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча ЮХИДИ бүлеге | Эчке расписание буенча | Эчке расписание буенча | 2-32-02 | |
| 12 | Lada Largus җиңел машинасы | ТР Министрлар кабинетының Баш | В325ЕТ | Гарипов И.Г. | 2-53-78 | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | вет. идарәсе дәүләт вет. инспекциясенең Саба тер. бүлеге | | | | |
| 13 | Lada Largus җиңел машинасы | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | А368ХН | Мәсгутов И.М. | 2-30-93 | |
| 14 | эчке расписание буенча җиңел машина | Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлеге | Эчке расписание буенча | Эчке расписание буенча | 2-32-02 | |
| 15 | Ford Transit санитар автомобиле | “Саба район үзәк хастаханәсе” ДАСУ | С972НН | Халиев И.Р. | 2-33-03 | |
| 16 | махсус КамАЗ АЦ-8.040.53228 | “ТР буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 129 янгын бүлеге” ФДКУ | М680РР | Эчке расписание буенча | 2-32-01 | |
| 17 | УАЗ 31512 җиңел машинасы | “Саба өйрәнү-сынау урман хуҗалыгы” ДБУ | Х396НО | Асатов Р.Р. | 4-42-17 | |
| 18 | сиптергеч | “Саба район дәүләт вет. берләшмәсе” ДБУ | | | | |
| 19 | сиптергеч | “ТР да Гигиена һәм эпидемиология үзәге” ФБССУнең Саба, Кукмара, Мамадыш районнарындагы бүлеге | | | | |

**Отряд командиры** ______________________________ **З.Р. Ганиев**

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районының
эпизоотиягә каршы җыелма
мобиль отряды турындагы
Нигезләмәгә 4 кушымта

## Отрядның шәхси составына хәбәр итү схемасы




Искәрмә. Бүлекчә командирлары шәхси составка үзләренең хәбәр итү схемасы буенча хәбәр итәләр.

**Отряд командиры _________________________ З.Р. Ганиев**

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районының
эпизоотиягә каршы җыелма
мобиль отряды турындагы
Нигезләмәгә 5 кушымта

**“Саба район дәүләт ветеринария берләшмәсе” ДБУнең дежур торучысына отрядның шәхси составына хәбәр итү һәм аны җыю буенча инструкция**

Отрядның шәхси составына хәбәр итү һәм аны җыю отряд командиры, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе карары буенча башкарыла ала.

Дәүләт ветеринария берләшмәсе дежур торучысы, отрядның шәхси составына хәбәр итү һәм аны җыю өчен команда (күрсәтмә) алганда, журналда алынган мәгълүматның датасын һәм вакытын, мәгълүмат бирүченең фамилиясен, исемен, атасының исемен, кыскача эчтәлекне, элемтә өчен телефон номерын теркәргә тиеш.

Дежур торучы отрядның шәхси составына хәбәр итүне телефон аша түбәндә бирелгән схема буенча гамәлгә ашыра.